УДК 82.091

***Н.Ш. Насыйбуллина***

# ТУКАЙНЫҢ ОСТАЗЫ – МИРХӘЙДӘР ЧУЛПАНЫЙ

В статье делается попытка раскрыть влияние деятельности и творчества малоизученного татарского поэта Мирхайдара Чулпаныя на мировоззрение Габдуллы Тукая, шакирда медресе «Мутыгия» города Уральска. Помимо Мутыгуллы и Камиля Тухватуллиных, на развитие поэтического таланта Г. Тукая оказал большое влияние и Мирхайдар Чулпаный. Автор аргументирует актуальность данной проблемы, делает краткий обзор биографии и творчества духовного наставника Тукая Мирхайдара Чулпаныя.

**Ключевые слова:** М. Чулпаный, Г. Тукай, поэт, наставник, татарская поэзия, медресе «Мотыгия», г. Уральск.

The article attempts to disclose the influence of the activities and work of the little-studied Tatar poet Mirkhaydar Chulpanyi on the worldview of Gabdulla Tuqay, the shakird of the Mutygiya madrasah in the Uralsk city. In addition to Mutygullah and Camille Tuhvatullina, Mirheydar Chulpaniy also had a great influence on the development of the poetic talent of G. Tuqay. The author argues that this matter is relevant, gives a brief overview of the biography and works of Tuqay's spiritual mentor Mirkhaidar Chulpanyi.

**Keywords:** M. Chulpanyi, G. Tuqay, poet, mentor, Tatar poetry, madrasah "Mutygiya", Uralsk.

Тукайның әдәби мирасы, вакытлар үтүгә карамастан, бөтен тирәнлеге белән ачыла гына бара. Шагыйрьнең көнкүрешен, иҗатын тулырак күзаллау максатыннан, аның белән аралашкан шәхесләр турында мәгълүматлар туплана. Шагыйрьнең егерме җиде еллык гомеренең унике елы Җаекта үтә. Җаекта яшәгән еллары Тукай тормышының үсү, җитлегү, кечкенә Апуштан бөек Тукайга әверелү чоры булып тарихка кереп кала. Габдулла Тукайның шигъри таланты үсешенә Мотыйгулла хәзрәт һәм Камил Мотыйгыйның зур йогынты ясавы барыбызга да мәгълүм. Ә шигъри остазы булган Мирхәйдәр Чулпаный турында мәгълүматлар юк диярлек. «Мотыйгыя» мәдрәсәсендә укыган Мирхәйдәр Чулпаный Оренбург губернасының Бозаулык шәһәреннән ерак булмаган Хөсәен авылында мулла вазифасын башкара. 1890 елда Оренбургта «Сәед бистәсе» исемле китабын бастырып чыгаруы билгеле [Хәмидуллин, б. 25]. Шагыйрь турында мәгълүматлар 1900 елда Оренбургта Б.А. Бреслин нәшриятында басылган «Гарәбидән мәнзумә мәүледеннәби тәрҗемәсе» дип исемләнгән китабында чагылган [Әхмәтҗанов, б. 76]. Чулпаный Тукайны якын күргән, үз шигырьләрен укып, аларның төзелешен аңлаткан. Бу исә Тукайның шигырь белеме өлкәсендә мәгълүматын шактый арттырган.

Җаек шәһәрендә шәкерт Тукай белән якыннан аралашкан Мирхәйдәр Чулпаный турында Тукай иҗатын өйрәнүче галимнәр аерым

фикерләр язып калдырсалар да, әлеге язмаларда шагыйрьгә бәйләнешле төгәл мәгълүматлар бик аз. Тукай энциклопедиясендә З.З. Рәмиев тарафыннан язылган мәкаләдә шуны күрәбез: «Мирхәйдәр, Бузулук шәһәре (хәзер Оренбург өлкәсе) янындагы бер авыл мулласы, шагыйрь. Яшьлегендә берара «Мотыйгыя» мәдрәсәсендә укыганлыктан, ул ел саен Уральскига килеп, бу мәдрәсәдә озаклап торып китә торган була. Истәлекләрдә аның Тукайны яратуы, еш кына әңгәмәләшүе әйтелә. Үзе язган шигырьләрен укуы, аларны ничек язуы турында сөйләве Тукайда шигырь язуга омтылыш тудырган (Мотыйгулла хәзрәттән гаруз гыйлеме турында дәресләр дә ала). К. Мотыйгый истәлегендә «бергәләп утырганда аларның «Хәраб итде бези, аһ, бу җәһаләт, / Нәләр янды безә, аһ, бу сәфаләт» дигән шигырьне бергәләп көйләп утыруларын ишет»үе языла. Тукайның исә Чулпаныйдан үрнәк алып, «Мотыйгыя» мәдрәсәсе назыйре В. Хәмидуллинга багышлап язган шигыре дә («Тугъды, көн тугар кеби..» дип башлана) китерелә » [Габдулла Тукай. Энциклопедия, б. 755].

Чулпаный «Тукай турында истәлекләр» китабында (Казан, 1986), «Тукай – ядкярләрдә» җыентыгында басылган «Габдулла мәрхүм Тукай хакында хосусый ядкәр» исемле «Че» тәхәллүсе белән бирелгән автор мәкаләсендә дә телгә алына [Тукай – ядкярләрдә, 2 т, б. 223]. Бу автор турында әлегә мәгълүмат булмавы һәм аның мәкаләсе беренче мәртәбә «Кояш» газетасының 1914 елгы 2 апрель санында, аннан соң авторы Галиәсгар Мөгыйн улы Гафуров-Чыгтайга (1867–1942) нисбәт ителеп, кыскартылган вариантта «Тукай турында хатирәләр»дә, «Че» тәхәллүсе белән «Тукай турында истәлекләр»дә басылуы әйтелә. «Хәйдәр мулла – Мирхәйдәр Чулпаный (сүз Мирхәйдәрҗан бине Сөнгатулла бине Зөлкарнәен әл-Чулпаный турында бара) үз вакытында Җаектагы «Мотыйгыя» мәдрәсәсен тәмамлаган һәм Оренбург губернасындагы (хәзерге Оренбург өлкәсенең Тоцкий районындагы) Хөсәен дигән авылда мулла вазифасын башкарган. Елга бер мәртәбә әлеге уку йортына килеп, берәр ай торып китә торган булган. Шул вакытларда Г. Тукай аның белән аралашкан».

Чулпаныйга кагылышлы беркадәр хәбәрләр күренекле татар язучысы Әхмәт Фәйзи әсәрләрендә [Фәйзи, б. 438], Рабит Батулланың «Апуш-Тукай» кыйссасында [Батулла, б. 75] язылган.

Мирхәйдәр Чулпаный һәм Габдулла Тукай арасындагы үзара танышлыкның барышын язучы Әхмәт Фәйзи «Тукай» романында образлы итеп бирә [Фәйзи, б. 349]. Чулпаныйны ул эзләнүчән, яңалыкка омтылучан, шәкертләрдә дә шушы сыйфатларны тәрбияләргә тырышкан кеше итеп сурәтли.

Әхмәт Фәйзи иҗатын өйрәнеп, аның әдәби осталыгын тикшерүгә багышланган хезмәтендә З. Шәйхелисламов әдипнең архивында Мирхәйдәр Чулпаныйга багышланган кызыклы мәгълүматлар туплануын яза [Шәйхелисламов, б. 83].

Мирхәйдәр Чулпаный хакындагы мәгълүматларны беренче булып фәнни әйләнешкә Ибраһим Нуруллин кертә. Тукай тормышын һәм иҗатын өйрәнүгә багышланган хезмәтендә ул: «Ел дәвамында Г. Тукай «Мотыйгия» мәдрәсәсендә укыганда шагыйрь Мирхәйдәр Чулпаный белән таныша. Чулпаный «Мотыйгия» мәдрәсәсен тәмамлаган яңа карашлы шагыйрь була. Г. Тукайда шагыйрьлек дәрте уятуга билгеле бер йогынты ясый. Шигырьләрен ул *(Мирхәйдәр),* остазлары Әбелманих Каргалый, Һибәтулла Салихов, Шәмсетдин Зәки кебек үк, «югары стильдә», ягъни авыр аңлаешлы корама телдә язган» [Нуруллин, б. 70], – дип яза.

Бу факт Ф.И. Ибраһимова һәм Ә.Х. Алиева төзегән «Габдулла Тукай. Тормыш һәм иҗат елъязмасы» [б. 15] исемле китапта да урын ала.

Чулпаный муллалык иткән Хөсәен авылы – хәзерге Оренбург өлкәсе Тоцкий районындагы Саиновка авылы. Бузулук елгасы буенда урнашкан авылга 1787 елда беренчеләрдән булып Казан губернасыннан гаиләсе белән күчеп килеп Хөсәен Ишмәтов нигез сала [Хасанова, Искандаров, б. 250]. Соңыннан Тимәш[1] авылыннан, 1795 елда Бөгелмә өязеннән ике гаилә, 1788 елда Спас округы Чәчәкле авылыннан, 1807 елда Казан губернасыннан 30 гаилә килеп төпләнә[2]. 1920 елга кадәр авылда мәчет һәм мәдрәсә эшли, ахун вазифасы (урыны) була. Г.Х. Хәсәнова авыл тарихын яктыртуга багышлаган мәкаләсендә имамнарның тормышын һәм эшчәнлеген яктыртуны максат итеп куймый.

Шагыйрьнең «Мотыйгия» мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң да Хөсәен авылыннан елына бер мәртәбә мәдрәсәгә килеп берәр ай торып китүе, Оренбургта 1900 елда Б.А. Бреслин матбагасында нәшер ителгән «Гарәбидән мәнзумә мәүледеннәби тәрҗемәсе»3 (дастан. – *М.Ә.*) китабының басылуы, Мирхәйдәр дигән исемнең Эстәрлебаш, Юлык якларында популяр булуы – болар аның чыгышы ягыннан Оренбург ягы кешесе булуына ишарә итә, дип язды танылган галим М. Әхмәтҗанов «Археографик экспедицияләр һәм Габдулла Тукай хатирәләрдә» исемле хезмәтендә [Әхмәтҗанов, б. 132]. Галим Хөсәен исемендәге авылларның – Дим буенда Әлшәй һәм Дәүләкән төбәгендә булганлыгын ачыклый. Аларны чагыштырып караганда, Әлшәй төбәгендәге Хөсәен авылы Эстәрлебаш һәм Оренбург кебек татар мәдәни үзәкләренә якынрак булганга, Чулпаныйның хезмәт урыны булырга мөмкин дип фикер йөртә [Әхмәтҗанов, б. 56]. Мирхәйдәрнең шигъри таланты турында әлегә бер юл дә мәгълүм түгеллеге турында да телгә ала. Аның Оренбургта билгесез кеше тарафыннан 1900 елда китабы чыгарылуын, Казанда кайбер әсәрләренең басылган булуына да ишарә ясый.

---

[1] Тимәш авылы – Татарстанның Лениногорск районындагы авыл.

[2] ГАОО, ф. 98, оп. 2, ед.хр. 15.

[3] «Гарәбидән мәнзумә мәүледеннәби тәрҗемәсе» – «Пәйгамбәрнең тууы турында гарәпчәдән тәрҗемә ителгән шигъри хикәя».

«Шагыйрьнең «Чулпаный» дигән тәхәллүсен аның яңа фикерле кеше күзлегеннән чыгып сайлап алган үз образы дип аңларга мөмкин», – дип яза галим һәм «Гарәбидән мәнзумә мәүледеннәби тәрҗемәсе» әсәренең транслитерациясен ясап хәзерге татар теленә тәрҗемә итә:

Аллаһ, Аллаһ исмене йад идәрем,
Вирде нигъмәт шөкринә бәс нидәрем.
Хәмедне ул вә сани сүзләрем,
«Фазылны дөньйа вә гукьба күзләрем.
Нурпакь әнбийәйә чук сәлам,
Әс-салават вә эссәлам дирем мадам.
Шуйлә нур кем шаэни ирди интикаль,
Мәркәз абә кирамә иттисаль.
Әһле бәйтә эстәдем хакъдин риза,
Һәб сәхабә табигинә иртиза.
Нә гүзәл зикер мәфәхирел-әнам,
Зи кәрам әнсаб үтәди тәмам.
Хак гинайәт әйләсә идем бәйан,
Мәүлидин назыйм хәсән әйлә гәйан.
Кыйл могәттар рух пакен йа сәлам,
Рух аглай салават илә сәлам.

Тәрҗемәсе:

*Аллаһ, Аллаһ исемен искә алырмын,*
*Бирде байлык, шөкер итми нишләрмен.*
*Аллаһыны искә алган сүзләрем,*
*Биргән нигъмәтләрне шөкер йөзеннән нишләрмен.*
*Икенче сүзләрем мактау булыр,*
*Дөнья һәм ахирәттә фазыйләт иясен күзләрмен.*
*Нурлы һәм пакь пәйгамбәрләргә күп сәлам,*
*Дога һәм сәлам диярмен даими.*
*Шулай итеп нур иясе булган җирдән күчте,*
*Хөрмәтле аталарның мәркәзенә кушылды.*
*Аллаһ Тәгаләдән пәйгамбәрнең туганнарыннан*
*Риза булуын сорадым.*
*Ни гүзәл зикер кешеләрнең мактаулысын искә алып,*
*Хөрмәтле нәсеб үтәде тәмам бурычын.*
*Аллаһы Тәгалә ярдәм итсә бәян итәрмен,*
*Шагыйрьнең тууын яхшы күр.*
*Хуш исле рухын пакь ит, я Аллаһ,*
*Бөек рухында дога белән сәлам.*

Шигырьдә без Чулпаныйның борынгыдан килгән язма поэзия традицияләрен дәвам итүен күрәбез. М. Әхмәтҗанов Чул-

паныйның имамлыгына, аның ислам фәлсәфәсен, аның абруй терәкләрен нык саклаучы булганлыгына басым ясый һәм шәхеснең XIX гасыр ахырларында татардагы ислам диненә карата Русия хөкүмәтенең тискәре сәясәтен нык тоеп яшәгәнлеген ассызыклый [Әхмәтҗанов, б. 132].

Мәдрәсә язма иҗат урыннарының берсе булган, шул сәбәпле борынгы поэзиядән килә торган традицияләр монда нык сакланган. Тормышның үзендә булган вакыйгаларга карата да яңа әсәрләр туган. Шул шартларда шәкерт-шагыйрьләр язма поэзиягә яңалыклар алып килгәннәр. Тукай үзе дә «Аң» шигырендә Чулпаный белән «Мотыйгия» мәдрәсәсе биналары кысасында әңгәмәләр уздырган вакытларын искә алып:

«Булса да ул чакта бездә керсез иман, саф күңел,
Күз һаман булды эренле, йөз дә саф һәм пакь түгел», –

дип яза һәм инде киләчәккә яңа караш, саф йөз белән карый башлау вакыты җиткәнен игълан итә.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк, Тукай иҗаты – меңьеллык татар шигъриятенең мөһим буыны, традиция һәм яңалык кушылуның күркәм бер үрнәге. Аның әсәрләрендә халкыбыз яшәешенең төрки чынбарлыгы һәм рухи тормышының әһәмиятле мәсьәләләре гәүдәләнеш таба. XX йөз башы татар шигърияте зур үсешкә ирешкән икән, моңа, әлбәттә, Тукай һәм аның остазы Мирхәйдәр Чулпаныйның да өлеше зур дип әйтергә була. Ләкин без Чулпаныйның тормыш юлын һәм иҗатын тирән һәм тулы яктырттык дип әйтүдән ерак торабыз, якын киләчәктә алар үстереләчәк, тирәнәйтеләчәк. Мәкалә әдипнең образын күз алдына китереп бастырырга, ул яшәгән чорның бөеклеген аңларга азмы-күпме ярдәм итә алса, куелган максатка ирешкән булырбыз.

**Әдәбият**

*Әхмәтҗанов М.И.* Археографик экспедицияләр һәм Габдулла Тукай хатирәләрдә. 2015. 132 б.

*Әхмәтҗанов М.И.* Габдулла Тукай һәм Мирхайдәр Чулпаный // Түгәрәк уен. 2014. № 2. Б. 56–58.

*Батулла Р.* Апуш-Тукай: кыйсса // Казан утлары. 2011. № 4. Б. 75–86.

Габдулла Тукай. Тормыш һәм иҗат елъязмасы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 271 б.

Габдулла Тукай. Энциклопедия / [баш мөх. З.З. Рәмиев]. Казан: Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2016. 864 б.

ГАОО, ф. 98, оп. 2, ед. хр. 15.

*Нуруллин И.* Габдулла Тукай. Казан: Татар. кит. нәшр. 1979. Б. 70–71.

Тукай турында истәлекләр / төз. И. Нуруллин, Р. Якупов. Казан: Татар кит. нәшр., 1986. 431 б.

Тукай – ядкярләрдә: 2 томда / төзүчеләр: Р.Ф. Исламов, Җ.С. Миңнуллин. Казан: Җыен, 2015. 2 т.: Мәкаләләр, шигырьләр, төрлеләр.

*Файзи А.* Тукай: роман. Казань,1985. 528 с.

*Фәйзи Әхмәт.* Әсәрләр. I том. Тукай. Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. Б. 438–448.

*Хасанова Г.Х* Саиновка (Хөсәен). *Искандаров Р.Ш.* Оренбургские татары: историко-энциклопедический очерк. – Казань: Татар.кн. изд-во, 2009. 271 с.

*Хәмидуллин Л.* Кичке шәфәкъ. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 255 б.

*Шәйхелисламов З.Р.* Аңлыем дип шагыйрь җанын... (Әхмәт Фәйзи иҗатында Тукай). Казан: Фикер. 2001. 144 б.

***Насыйбуллина Нуридә Шәйдулла кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибрагимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге өлкән фәнни хезмәткәре*